ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 19 февралендә
кабул ителде

## 1 статья

«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 6 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш); 2026, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $1^1$ өлештә «филиаллары һәм вәкиллекләре» сүзләрен «вәкиллекләре, филиаллары һәм бүтән аерымланган структур бүлекчәләре» сүзләренә алмаштырырга;

2) $1^2$ өлештә «филиалларына һәм вәкиллекләренә» сүзләрен «вәкиллекләренә, филиалларына һәм бүтән аерымланган структур бүлекчәләренә» сүзләренә алмаштырырга, «филиаллары һәм вәкиллекләре» сүзләрен «вәкиллекләре, филиаллары һәм бүтән аерымланган структур бүлекчәләре» сүзләренә алмаштырырга;

3) 12 өлештә «филиалының» сүзеннән соң «һәм бүтән аерымланган структур бүлекчәсенең» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 21 февраль
№ 8-ТРЗ